# YearCompass

2023 «|» 2024

# İsänme

## Bu närsä?

Bu – YearCompass, tögälräk äytkändä, sezneñ şäxsi Yıllıq Kompasığız.

Bu - uzğan yıl turında uylanıp, aldağısın planlaştırırğa mömkinlek birüçe buklet. Centekläp saylanğan sorawlar häm künegülär yärdämendä YearCompass sezgä başqarğan ğämälläregezneñ ezleklelegen açıqlarğa häm şäp yıl proyektın tözergä bulışır.

Buklet ayırım ike öleştän tora. Berençe yartısı uzğannı analizlaw, sabaq alu, bäyrämçä ozatu öçen. İkençe yartısı isä kiläçäk turında. Sez xıyallanırsız, plannar qorırsız häm yaña yıldan mömkin qädär kübräk qänäğätlek xise alırğa äzerlänersez.

## Bukletnı tutıru öçen miña närsälär kiräk?

Qäläm, berniçä säğätkä iğtibarığıznıñ bukletqa yünälgän bulıı häm ayıq aqıl, ğädel fiker.

## Min moni komanda belän eşli alammı?

Älbättä! Duslarıñnı cıy. Barığızğa da citärlek itep bukletlarnı bastırıp alığız, awlaq urın tabığız. Härkem üzeneñ YearCompass-ın üze tutırırğa tieş, ämma sez tänäfes yasap, künegülär buyınça fiker alışa, uy-xisläregez belän büleşä alasız.

Zinhar, üzeñnän çığıp qına eş itmä, duslarıñnıñ uyların belderüdä çikläre bulırğa mömkin. Härkem üzenä uñay bulğan närsälär belän genä büleşergä xaqlı.

# Äzerlän

Cıyın.
Kiräkle bulğan bar närsäne äzerläp quy häm
äylänä-tirändä üzeñä qulay şartlar buldır.
Küzläreñne yom da, biş tapqır tirän itep sulış al, sulışıñnı çığar.

Närsäder kötüeñne çitkä quy.

Äzer buluıñnı toyuğa, Başla.

# Uzğan yıl

## Kalendar' bitläreñne barlap çıq.

Atnadan-atnağa uzğan yıl kalendaren qara. Ähämiätle waqiğanı oçratasıñ ikän, duslar belän küreşüme ul, ğailä belän uzğan waqiğamı, ällä inde möhim burıçmı, monda yazıp quy.

# Uzğan yıl

## Bu - uzğan yılımnıñ närsä turında bului xaqında

Bez törle, ämma ber-bere belän bäylängän tirälektä yäşibez. Tübändä kürsätelgän ölkälärne qara da, üz aldıña soraw quy: şularnıñ härqaysında nindi möhim waqiğalar buldı? Cawaplarıñnı yazıp bar.

şäxsi tormış, ğailä

karyera, belem alu

duslar, cämğiät

yal, hobbi, icat

fizik sälämätlek, sport

psixologiä, üzeñne tanıp belü

sine sürätläwçe ğädätlär

iñ yaxşı irtägä*

* Bu yılda dönya moña qädärgedän yaxşıraq bulsın öçen ni eşläden?

# Uzğan yıl

## Uzğan yılım buyınça altı soraw

Min qabul itkän iñ ziräk qarar...

Min alğan iñ zur sabaq...

Bu yıldağı iñ zur täwäkkällegem...

Yılnıñ iñ zur sürprizı...

Başqalar öçen eşlägän iñ möhim ğämälem...

Min tämamlağan iñ zur eş...

# Uzğan yıl

## Uzğan yılım buyınça altı soraw

Barısınnan da kübräk ni belän ğorurlanasıñ?

Siña ayıruça yoğıntı yasağan öç keşe?

Kemnärgä sin ayıruça yoğıntı yasadıñ?

Närsäne tämamlap ölgerä almadıñ?

Üzeñ turında yasağan iñ zur açış?

Barısınnan da bigräk sin närsä öçen räxmätle?

# Uzğan yıl

## İñ yaxşı mizgellär

Uzğan yılda onıtılmaslıq tä’sir qaldırğan, küñelle mizgellärne surätlä. Bu bittä şunıñ räsemen yasa. Sin ul waqıtta nilär xis itteñ? Yänäşäñdä kemnär buldı? Sez ni eşli idegez? Şul mizgeldäge nindi is, awaz yäki tämnärne xäterliseñ?

# Uzğan yıl

## Minem iñ zur öç uñışım

Uzğan yılda ireşkän xälitkeç öç uñışıñnı yazıp quy.

Moña ireşü öçen sin ni eşlädeñ?

Siña kem, ni räweşle yärdäm itte?

## Min duçar bulğan iñ zur öç sınawım

Siña uzğan yıl kitergän öç zur sınaw turında yaz.

Siña kem yäki närsä bu sınawnı uzarğa yärdäm itte?

Bu sınawlarnı uzğanda üzeñ turında nilär beldeñ?

# Uzğan yıl

## Ğafu itü

Uzğan yılda inde ğafu itärgä waqıt citkän ğämäl-oçraqlar buldımı? Äle dä siña tınğılıq birmäwçe eşlär yäki süzlär bardır? Bälki, sin närsä öçen dä bulsa üzeñä açulanıp yöriseñder? Bolarnı yazıp quy. Üzeñä qarata räximle bul häm ğafu it.*

* Üzeñne kiçerergä äzer tügelseñ ikän, barıber yaz. Kem belä, süzlär moğciza tudıruçan.

# Uzğan yıl

## Buşanu

Menä-menä küñeldän taşıp çığarğa torğan tağın nilär bar? Yaña yıl  başında siña nidän arınırğa kiräk? Bolar xaqında yaz, räsemen yasa, uyla - häm buşan.

# Uzğan yıl

## Uzğan yıl öç süzdä

Sineñ uzğan yılıñnı taswirlawçı öç süzne yaz.

## Uzğan yıl kitabım

Uzğan yılıñ turındağı kitap yäki filmıñnı niçek isemlär ideñ?

## Saw bul, uzğan yıl!

Tağın nider yazarğa teläsäñ yäki kem beländer sawbullaşasıñ kilsä, monı xäzer eşlä.

## Sin uzğan yılğa näticälär yasadıñ.

Sin äle berençe öleşne genä tämamladıñ.
Tirän sulış alıp quy.

Yal it.

YearCompass oşıymı? Anıñ turında duslarıña da citker, sıltama belän büleş!
Bezgä mömkin qädär kübräk yärdäm itärgä bulışığız.

**https://yearcompass.com**

# Kiläse yil

2024

# Kiläse yıl

## Zurdan qubip xıyallan

Kiläse yılıññıñ nindi buluın telär ideñ? İñ xäyerle oçraqta ul niçek ütär? Ni öçen bu yıl iskitmäle bulırğa tieş? Yaz, räsemen yasa, kötkäneñne irekkä cibär häm xıyallarıñnan qurıqma.

# Kiläse yıl

## Bu - kiläse yılımnıñ nindi bulaçağı xaqında

Tormışıñnıñ törle ölkälären barla häm härbersenä kiläse yıl öçen maqsat bilgelä. Uyıñdağı maqsatlarnı käğäzgä töşer. Bu - alarnı çınbarlıq itüdä berençe adım.

ŞÄXSI TORMIŞ, ĞAILÄ

KARYERA, BELEM ALU

DUSLAR, CÄMĞIÄT

YAL, HOBBI, ICAT

FIZIK SÄLÄMÄTLEK, SPORT

PSIXOLOGIÄ, ÜZEÑNE TANIP BELÜ

SINE SÜRÄTLÄWÇE ĞÄDÄTLÄR

IÑ YAXŞI IRTÄGÄ*

* Dönya bügengegä qarağanda yaxşıraq bulsın öçen kiläse yılda ni eşläyäçäkseñ?

# Kiläse yıl

## Yaña yılnıñ tılsımlı öçlege

Üzemdä bu öç närsäne yarataçaqmın.

Bu öç närsäne küñelemnän alıp taşlap, alğa taba baraçaqmın.

Min ayıruça ireşergä telägän öç närsä.

Bu öç keşe awır waqıtta minem terägem bulır.

Bu öç närsäne min tatıp-eşläp qararmın.

Bu öç närsägä min „yuq” dip äytäçäkmen.

# Kiläse yil

## Yaña yılnıñ tılsımlı öçlege

Bu öç närsä belän äylänämdä uñaylıq buldıram.

Bu öç närsäne här irtä sayın eşläyäçäkmen.

Bu öç äyber belän üzemne daimi söyenderäçäkmen.

Min bu öç urında bulaçaqmın.

Älege öç yul belän min iñ yaqın keşelär belän elemtälärne caylap, aralaşunı däwam itep toraçaqmın.

Älege öç büläkne üzemä uñışlarım öçen biräçäkmen.

# Kiläse yıl

## Kiläse yılıma altı teläk

Bu yılda min ozaqqa suzmıy ğına eşläyäçäkmen...

Bu yılda min energiäne menä qaydan alam...

Bu yılda min menä nindi oçraqlarda iñ qıyuı bulaçaqmın...

Menä nindi oçraqlarda min bu yılda „äye” dip äytäçäkmen...

Bu yılda üzemä kiñäş itäm...

Bu yıl minem öçen üzençälekle bulaçaq, çönki...

# Kiläse yıl

## Kiläse yılğa äyter süzem

Sineñ yaña yılda kötkännäreñne çağıldıruçı süzne tap. Bu süz siña ikençe sulış örer. Xıyallarıña barırğa, köräşergä etärgeç bulır.

## Yäşeren teläk

Uy-xıyallarıña irek bir. Kiläse yılğa nindi yäşeren telägeñ bar?

## Qotlıybız, sin äle genä aldağı yılıñnı planlaştırdıñ!

Fotoğa töşerep häm #yearcompass häştägen qullanıp,
bezneñ xaqtağı mäğlümat belän urtaqlaş.

# Kiläse yıl

## Min ışanam, yaña yılda mömkin bulmağan ber närsä dä yuq.

Tutırılu köne:

İmza:

Budapeştta (Macarstan) xalıqara komanda tarafınnan çın yöräktän äzerlände.

**https://yearcompass.com/tt**

YearCompass oşıymı? Anıñ turında duslarıña da citker, sıltama belän büleş!
Bezgä mömkin qädär kübräk yärdäm itärgä bulışığız.

Ägär dä sin orfografik häm grammatik xatalarğa yulığasıñ ikän, bezgä saytıbız aşa xäbär it.

Bu bukletnıñ eçtälege Creative Commons şirkätendäge
Atributsiä — Kommersiäle bulmağan — Şul uq şartlarda urtaqlaşu 4.0
Xalıqara litsenziäse nigezendä litsenziälängän.